# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында юллар фонды турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

1 статья. «Татарстан Республикасында юллар фонды турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №3; 1993, №3; 1994, №1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, №7-8, №9; 1996, №7; 1997, №7; 1999, №3; 2000, №1(1), №6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «автотранспорт чараларын Татарстан Республикасыннан читтә сату-алу, алмашу, лизинг юлы белән сатып алучы физик затлар, шулай ук» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2 пунктта «; физик затлар өчен - Татарстан Республикасыннан читтә сатып алынган автотранспорт чараларының сатылу бәясеннән 3%» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

4 пунктта:

2, 3, 4 абзацларны төшереп калдырырга;

5 һәм 6 абзацларны 2 һәм 3 абзацлар дип санарга.

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 19 декабре
№ 518